Татарстан Республикасы

Казан шәһәре Авиатөзелеш районы “134 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе”

гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе

| **Каралды:** | **Килешенде :** | **Расланды:** |
| --- | --- | --- |
| МБ утырышы беркетмәсе №1<br>МБ җитәкчесе<br>__________ А.Җ. Зәйнуллина<br>Дата 25.08.2015 | Директор урынбасары<br>_________ Н.Б .Мусина<br>Дата .08.2015 | Мәктәп директоры<br>_________ А.С.Петров<br>Педагогик совет утырышы беркетмәсе №1<br>Дата .08.2015 |

***Эш программасы***

Фән- татар теле

7 “А” сыйныфы, рус төркеме.

Ф.И.О.- Зәйнуллина Альмира Җиһангәрәй кызы, югары квалификацион категорияле

Гамәлдә куллану вакыты- 2015/16 нчы уку елы.

Казан- 2015 -2016 нчы уку елы

**Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләренең рус төркемендәге 7нче сыйныф укучылары өчен татар теле буенча белем бирү программасына аңлатма язуы**

**Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:**

1. Россия Федерациясе конституциясе 12.12.1993 (РФ Конституциясенә 30.12.2008 елда №6-ФКЗ, 30.12.2008 елда №7-ФКЗ,21.07.2014 елда №11-ФКЗ белән кергән үзгәрешләр исәпкә алынды.
2. Татарстан Республикасы Конституциясе 6.11.1992(үзгәрешләр һәм әстәмәләр белән)
3. .29.12 2012 нче елда кабул ителгән 273 нче номерлы "Россия Федерациясендә Мәгариф турында" Федераль кануны.
4. 22.07. 2013 нче елда кабул ителгән 68 нче номерлы "Мәгариф турында" Татарстан Республикасы кануны.
5.8.07.1992 нче елда кабул ителгән 1560 – XXII номерлы "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" ТР кануны.
6.. 17.12.2010 елда кабул ителгән 1897 номерлы төп гомуми белем бирүнең(ООО) Федераль дәүләт белем стандарты..
7.ТР Мәгариф министрлыгының 7699/12 номерлы боерыгы, 23.06.2012 ел "Об учебных планах для 1-11 классов школ РТ, реализующих основные образовательные программы начального общего образования и основного общего образования в соответствии с ФГОС общего образования".
8. ТР Мәгариф министрлыгының 9807/12 номерлы хаты, 13.08.2012 ел "О преподавании татарского государственного языка в общеобразовательных учреждениях РТ" һәм №9777/12 номерлы хаты, 13.08.2012 ел "Об изучении татарского языка и литературы в образовательных учреждениях".
9."Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар " 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011 нче ел. ( Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы. 1-11 нче сыйныфлар , Казан: Татар китап нәшрияты, 2011. Төзүчеләр: Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева (программа федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) нигезләнеп төзелгән).
10. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгының 2015/2016 нчы уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре.Методик тәкъдимнәр.Казан. 2014ел
11. СанПиН 2.4.2.2821-10 "Гомуми белем бирү учрежденияләрендә укыту өчен шартлар һәм укытуны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр" (РФның баш дәүләт санитар табибының 189 нчы номерлы карары. 29.12.2010 ел)
12. Казан шәһәре Авиатөзелеш районы "134 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015/2016 нчы уку елына уку-укыту планы.

Дәреслек: Хайдарова Р.З.,Малафеева Р.Л.Татар теле.7 нче сыйныф. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек ( татар телен өйрәнүче укучылар өчен). Казан, "Татармультфильм "нәшрияты, 2014.

**Укыту фәненең уку планында тоткан урыны**

Укыту планында каралганча, татар теле дәресләре өчен эш программасы атнага 3 сәгать исәбеннән, елга 105 сәгатькә төзелде.

**Эш программасы структурасы**

Татар теленең эш программасы түбәндәге өлешләрдән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укытуның планлаштырылган нәтиҗәләреннән, укыту-методик, материаль-техник мәгълүмат бирү чыганакларыннан.

**Эш программасының эчтәлеге**

Эш программасының һәм белем бирүнең **төп максаты -** гамәли максат: телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә-көнкүрешкә, уку хезмәтенә бәйле сөйләм ситуацияләре кысаларында белем бирү һәм күнекмәләрен үстерү.

Бу максатка ирешү өчен, түбәндәге **бурычлар куела:**

1. Укучыларда татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләрен булдыру.
2. Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү.
3. Дөрес язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен булдыру.
4. Төрле жанрдагы татар текстларын аңлап укуга өйрәтү.
5. Татар теленең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик нигезләрен һәм үзенчәлекле тел күренешләрен гамәли үзләштерү.

Татар теле дәресләрендә, белем бирү белән бергә, **тәрбияви бурычны** да үтәү мөһим. Аңа ирешү өчен, татар сөйләм этикеты үрнәкләрен кулланып, әңгәмә корырга, фикер йөртергә, хәбәр итәргә күнектерү.

Татар дөньясына караган милли традицияләр, ризыклар, бәйрәмнәр, уеннар, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру һәм татар әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте турында мәгълүмат җиткерү сорала.

Гомуми белем мәктәбендә татар теле дәресләре укучыларның сөйләм телен үстерүгә юнәлтелә, бу исә аларның **тыңлап аңлау, сөйләү һәм сөйләшү, уку, язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен формалаштыруны** үз эченә ала.

Грамматикага өйрәткәндә, укучыларның ана теле үзенчәлекләрен исәпкә алу прицибы укытучы игътибарыннан читтә калмаска тиеш, чөнки татар һәм рус телләрендәге сөйләмдә сүзләрне һәм җөмләләрне үзара бәйләү закончалыклары күпкә аерылалар; шуңа күрә татар сөйләмендәге иң актив җөмлә калыплары рус телендәге калыплар белән чагыштырылырга, гамәли үзләштерелергә тиеш.

Программа белем бирү учреждениесенең фәннәрне тирәнтен өйрәнү юнәлешле булуын искә алып төзелә. 7- сыйныфта чит тел тирәнтен өйрәнелә, шул сәбәпле, программа гамәлдәге базис план буенча атнага 3 сәгать исәбеннән төзелә.

***5-9 нчы сыйныф укучыларының белем дәрәҗәсенә таләпләр:***

**Тыңлап аңлау** — аерым авазларны, иҗек калыпларын, сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләрне, бәйләнешле текстларны ишетеп, мәгънәләрен һәм эчтәлекләрен аңларга өйрәтү.

**Диалогик сөйләмгә өйрәткәндә**, укучыларны чынбарлыктагы ситуацияләргә куеп карау кирәк. Татарча аралашырга өйрәтү өчен, укучыларның мәктәптәге, өйдәге, урамдагы һәм җәмәгать урыннарындагы көндәлек тормышыннан чыгып, үрнәк диалоглар тәкъдим ителә. Сорау, җавап, килешү-килешмәү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү, аралашуда катнаша, аны туктата һәм яңадан башлый белү, парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү,

ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү, терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белүгә өйрәтү.

**Монологик сөйләмгә өйрәтү** Программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлекле лектә текст төзи һәм аның эчтәлеген сөйли белү, конкрет ситуациягә үз карашыңны әйтә, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү, аерым кешеләрне, әйберләрне табигать күренешләрен, хайваннарны тасвирлауга, сыйныф, мәктәп, авыл, шәһәр тормышы һ. б. турында хәбәр итүгә, укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген план буенча сөйләп бирүгә кайтып кала.

**Укуга өйрәткәндә**, рус телле балалар татар хәрефләрен танып, алар белдергән авазларны дөрес әйтергә, алга таба сәнгатьле итеп, йөгерек һәм аңлап укырга, яңа сүзләрне сүзлектән табарга, таныш булмаган текстны эчтән укып, аның төп фикерен таба белергә өйрәтү.

**Язуга өйрәтү** татар алфавитындагы хәрефләрнең дөрес язылышын истә калдыру; сүзләрне иҗекләргә бүлеп, юлдан юлга дөрес күчерү кагыйдәләрен үзләштерү; сөйләмдә актив кулланыла торган сүзләрне орфографик дөрес язу күнекмәләрен үстерү; нокталар урынына кирәкле сүзләрне куеп яки җәяләр эчендә бирелгән сүзләрне кирәкле формада кулланып, җөмләләрне күчереп язу.

**Язма сөйләмгә өйрәтү**, терәк сүзләр, сүзтезмәләр һәм үрнәк җөмләләргә нигезләнеп, өйрәнелә торган лексик тема яки бирелгән ситуация буенча җөмләләр яза белү. Укучылар язма рәвештә үзләренең гаиләләре, мәктәпләре, сыйныфташлары һәм дуслары, яшәгән шәһәрләре яки авыл турында кечкенә күләмле хикәяләр язарга өйрәнәләр. Рус теленнән татарчага тәрҗемә итү дә язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерүгә китерә. Укучыларның уку һәм язу күнекмәләре тыңлап аңлау һәм сөйләү нигезендә үстерелә.

Укучыларда **фонетик күнекмәләр** булдыру өчен, түбәндәгеләргә игътибар итү мөһим: татар теленә генә хас булган авазларның әйтелешен үзләштерү; татар һәм рус телләрендә уртак булган, ләкин әйтелешләре белән аерылган авазларны чагыштырып өйрәнү; авазларны сүзләрдә, сүзтезмәләрдә, җөмләләрдә, бәйләнешле сөйләмдә дөрес әйтүгә ирешү. Бу төр күнекмәләр булдыру өстендә эзлекле эшләү генә укучыларның сөйләмендәге фонетик хаталарны бетерергә мөмкинлек бирә.

Укучыларның **лексик күнекмәләрен** үстерү өчен, сүзләрнең әйтелешен, язылышын, мәгънәсен, ясалышын, башка сүзләр белән бәйләнешен, сөйләмдә кулланышын үзләштерү шарт. Моның белән беррәттән, татар һәм рус сүзләрнең мәгънә ягыннан аермаларын күрсәтеп бару да, рус телендә эквивалентлары булмаган сүзләрне аңлатып бирү дә сорала.

Укучыларның **грамматик күнекмәләрен** үстерү - төрле сүз төркемнәренең морфологик формалары, ясалышлары белән таныштыру, сүзләрнең җөмләдә үзара бәйләнеш чараларын үзләштерү һәм кагыйдәләрен белү дигән сүз. Татар телен икенче тел буларак укытканда, лексик-грамматик материалны синтаксик нигездә үзләштерү принцибына таянып эш итү кирәк, чөнки сүзләр башка сүзләр белән бәйләнештә булганда гына, җөмлә, гомумән, сөйләм барлыкка килә.

### VII сыйныфта татар теленнән үзләштерелергә һәм камилләштерелергә тиешле гомумкүнекмәләр

***Уку эшчәнлеген оештыра белү юнәлешендә***

1.Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.

2.Эшне планлаштыра белү.

3.Эшнең дөреслеген тикшерү.

4.Эш сыйфатына бәя бирү.

***Китап, өстәмә мәгълүмат белән эш итү***

1.Дәреслек белән эш итә белү.

2.Төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эш итә белү.
3.Төрле текстлар белән эш итү.
4.Белемнәрне системалаштыру өчен таблица, график , схемалардан файдалану.
5.Эчтәлекне аңлап, тиешле тизлектә, дөрес уку: -уку елы башында -70-80 сүз; -уку елы ахырында-80-90сүз;
6.Сүзлекләрдән файдалана белү.
7.Китапханәдә каталог белән эш итә белү.
8.Аудио-видео белән эш итә белү.

***Фикерләү белән бәйле күнекмәләр***

1.Уку мәсьәләсен куя белү.
2.Яңа теманы аңлауга мотив тудыру.
3.Танып белү активлыгын үстерү.
4.Төшенчә, термин,кагыйдә,закончалыкларны аңлап кабул итүкүнекмәләрен камилләштерү.
6.Тикшеренү ысуллары:
-модельләштерү;
-охшатып эшләү.
7.Логик алымнардан чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау күнекмәләре булдыру.

***Телдән һәм язма сөйләм үстерү һәм аралаша белү юнәлеше***

1.Телдән сөйләм:
- сорауны формалаштыра белү һәм тулы җавап бирә белү күнекмәсе;
-тәрҗемә итү күнекмәсе.
2.Язма сөйләм:
- күчереп язу;
- фикер йөртү элементлары кертеп, әзер план буенча бирелгән диалог, монолог язу
- изложение язу

**7нче сыйныфны тәмамлаучы рус телендә сөйләшүче балалар үзләштерергә тиешле белем-күнекмәләр**

-татар һәм рус телләрендә уртак булган, ләкин әйтелешләре белән аерылган авазлы сүзләрне дөрес әйтә белү;
- авазларны сүзләрдә, сүзтезмәләрдә, җөмләләрдә дөрес әйтүгә ирешү һәм сингармонизм законының асылына төшенү;
- сөйләмне орфоэпик һәм орфографик яктан дөрес оештыра белү;
- исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш кебек мөстәкыйль сүз төркемнәре турында беркадәр мәгълүматлы булу;
- татар телендә җөмлә төзелеше, җөмлә кисәкләре турында төшенчәне үзләштерү һәм куллана белү;
- коммуникатив максатларны аңлап, диалогик аралашуда катнашу;
- төрле аралашу сфераларыннан чыгып,телдән яки язмача үз фикереңне белдерүгә ирешү;
- тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле монологик сөйләм төзи алу;
- тиешле (1350сүз) күләмендә татар сүзләрен яттан белү.

**Тел чаралары һәм аларны куллану күнекмәләре:**

Орфография һәм орфоэпия кагыйдәләрен программага кертелгән эчтәлектә дөрес куллана белү.

Сөйләмнең фонетик ягы

Сөйләмдә татар авазларының үзенчәлекләрен саклау, аларны ишетеп аера белү. Транскрипция билгеләре. .Хикәя, боеру, тойгылы җөмләләрнең ритмик-интонацион үзенчәлекләре. Санау интонациясе. Сөйләм этикеты үрнәкләренең интонациясе.

Сөйләмнең лексик ягы

Программа кысаларындагы аралашу тематикасына караган лексик берәмлекләрне тану һәм куллана белү. Гади тотрыклы гыйбарәләр. Татар сөйләм этикеты берәмлекләре. Татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләр. Алынма сүзләр. Сүз ясалышы ысуллары: парлы, кушма һәм тезмә сүзләр.

Сөйләмнең грамматик ягы

Сөйләмдә исем, сыйфат, сан, рәвеш, алмашлык, фигыль (аралашуда киң кулланылыштагы төркемчәләре) мөстәкыйль сүз төркемнәрен тану һәм куллану.

Процессның башлануын, дәвам итүен, тәмамлануын, теләкне, мөмкинлек/мөмкин түгеллекне, кирәклек/кирәк түгеллекне белдерә торган модаль мәгънәле аналитик фигыльләрне куллану.

Бәйлек һәм бәйлек сүзләр, кереш сүзләрнең җөмләдә кулланылышы.

Сөйләмдә теркәгечләр һәм кисәкчәләрне куллану.

Хикәя, сорау, боеру җөмләләр. Татар җөмләсендә сүз тәртибе. Раслау һәм инкарь җөмләләр. Гади җәенке җөмләләр. Тиңдәш кисәкле җөмләләр. Һәм, ә, ләкин, чөнки теркәгечләренең җөмлә төзүдә кулланылышы.

**Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр**

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәниятказ карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

- Укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;
- коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә арашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;
- “Татар теле һәм әдәбияты” предметынакарата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыруһәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

Төп белем бирү баскычында татар теле һәм әдәбиятын укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән

эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә*;* укучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.
- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.
- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче,максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.
- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

Төп гомуми белем бирү баскычын төгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата
түбәндәге шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана:
- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
- “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”,төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

| **Программа материалының эчтәлеге** | |
|---|---|
| 1. Ясалышы буенча сыйфат төрләре.<br>2. Рәвеш төркемчәләре.<br>3. Теләк фигыльнең 1нче зат берлек һәм күплек сан формалары.<br>4. Сыйфат фигыльнең хәзерге һәм үткән заман формалары белән | 7. Җыючы (һәм, да-да, та-та,ни...ни), каршы куючы (ләкин, ә, әмма), бүлүче (я, яки) теркәгечләре белән җөмләләр төзү күнекмәләрен системалаштыру.<br>8. Ияртүче (әгәр, шуңа күрә) теркәгечләрне сөйләмдә куллану. |

| | |
|---|---|
| таныштыру.<br>5. Хәл фигыль белән таныштыру.<br>6. Исем фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 9. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә өйрәтү.<br>10. Җөмләнең баш кисәкләре: ия һәм хәбәр, алар арасында сызык куелу очраклары белән таныштыру. |

**Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек 7 нче сыйныф (105 сәг.)**

| **тематик эчтәлек, якынча сәгатьләр саны** | **Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат** |
|---|---|
| **Алдагы уку елында үткәннәрне кабатлау (6 сәг.)** бәйрәм белән котлый белү; бер-береңә комплиментлар әйтә белү. Яңа уку елына әзерлек турында сөйләшү.Сорауларга җавап бирә белү | аерым фикерләрне исбатлый һәм кире кага белү, сүз төркемнәре буенча белгәннәрне сөйләмдә куллана алу |
| **Белем һәм тормыш (21 сәг.)**<br>Классташларның укуы, билгеләр алуы, өй эшен эшләү, дәрестә катнашу. Уку-язу әсбаплары, аларны тәртиптә тоту. Яхшы уку серләре, яхшы уку өчен кирәкле сыйфатлар. | Яңа уку елындагы яңалыклар, җәйге ялны ничек уздыру, классташларыңның ничек укуы, нинди билгеләр алу, өй эшен ничек эшләү, дәрестә ничек катнашу турында сөйләшү. Начар билгегә үз карашын әйтә белү. Уку-язу әсбапларын тәртиптә тоту, яхшы уку серләре, яхшы уку өчен нинди холык сыйфатлары кирәклеге турында сөйләшү. |
| **Без бергә ял итәбез (38 сәг.)**<br>Буш вакыт: файдалы, файдасыз үткәрү. Яшьтәшләрнең үз-үзләрен җәмгыять урыннарында тотышы. Яшүсмерләрнең мөнәсәбәтен дә алдашу, ялганлашу. Яшьтәшләр белән бәйрәмнәрне оештыру, уздыру | Буш вакыт. Буш вакытны файдалы, файдасыз үткәрү. Яшьтәшләрнең үз-үзләрен җәмгыять урыннарында тотышы турында сөйләшү, бәя бирә белү.<br>Яраткан шөгылең турында сөйли белү.<br>Спорт түгәрәкләренә йөрү, спорт уеннарында катнашу, спорт чараларын, тапшыруларын карау турында сөйләшү. |
| **Өлкәннәр һәм кечкенәләр (19 сәг.)**<br>Өлкәннәр һәм кечкенәләрнең гаиләдә үзара мөнәсәбәтләре. Өлкәннәрдән рөхсәт сорау. Гаиләдә бергә бәйрәмнәр үткәрү. | Өлкәннәр һәм кечкенәләрнең гаиләдә үзара мөнәсәбәте, кушкан эшкә җаваплы караш турында сөйләшү. Өлкәннәргә үзеңнең кая барырга, нишләргә теләгәнеңне, кайчан кайтасыңны әйтә белү, өлкәннәрдән рөхсәт сорый белү. Гаиләдә бергә бәйрәмнәр үткәрү, әти-әниләрне бәйрәм белән котлау турында сөйли белү. |
| **Без Татарстанда яшибез (13 сәг.)**<br>Татарстанның территориясе, аның географик урыны. Татар композиторы, Сара Садыйкова. | Татарстанның табигате, аның табигый байлыклары турында сөйли белү. Туган як табигатенә карата үз фикереңне белдерә белү.Татарстанның территориясе, аның географик урыны. Атаклы композитор Сара Садыйкова турында сөйли белү. |
| **Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау (8 сәг)** | |

| **Практик өлеш** | 1нче чирек | 2нче чирек | 3нче чирек | 4нче чирек | Еллык |
|---|---|---|---|---|---|
| Мөстәкыйль эш | 1 | - | - | - | 1 |
| Контроль эш<br>(“Без бергә ял итәбез” бүлеген кабатлау буенча административ контроль эш-2 чирек) | 2 | 1+1(ад) | 1 | 2 | 7 |
| Тест | - | -- | 2 | 1 | 3 |
| БСҮ | 3 | 3 | 3 | 3 | 12 |
| Сочинение | - | - | 1 | - | 1 |
| Аудирование | 1 | - | - | 1 | 2 |
| Сүзлек диктанты | - | 1 | 1 | | 2 |

| Чирек | 1 | 2 | 3 | 4 | ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Сәгатьләр | 27 | 21 | 30 | 27 | 105 |

**Милли-региональ компонент**

1. 10-дәрес. Хикәя фигыльләрнең юклык формасы. Каюм Насыйри белемле булуның кыйммәте турында.
2. 20-дәрес. Боерык фигыльләрне кабатлау. ”Казанда Милли китапханә” тмасына б.с.ү.
3. 31-дәрес. Рәвешләрне кабатлау. “Казан парклары” темасына д.с.ү.
4. 50-дәрес. Тезүче теркәгечләр.“Казан театрлары” темасы буенча б.с.ү.
5. 65-дәрес. Җөмләнең иярчен кисәкләре. Р.Хафизованың “Әти кайткан көн”хикәясеннән җөмләләр тикшерү
6. 89-дәрес. “Татарстан республикасы” темасы буенча аудирование
7. 93-дәрес. “Татарстанның кошлар дөньясы” темасы буенча проект эше

**Татар теленнән календарь-тематик план 7класс, рус төркеме**

| № | Дәрес темасы | Материалны үзләштерүнең көтелгән нәтиҗәләре | | |
|---|---|---|---|---|
| | **1 нче чирек - 27сәг. 1. Алдагы уку елында үткәннәрне кабатлау - 6 сәг.** | | **план** | **факт** |
| 1. | “Җәйге каникулдан соң очрашу” темасы буенча лексика. | бәйрәм белән котлый белү; бер-береңә комплиментлар әйтә белү. Яңа уку елына әзерлек турында сөйләшү.Сорауларга җавап бирә белү, аерым фикерләрне исбатлый һәм кире кага белү, фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү, шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру | | |
| 2. | Исемнәрне кабатлау. | Исем буенча белгәннәрне гомумиләштерү, сөйләмдә дөрес куллана алу, логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, нәтиҗәле эш алымнарын табу. Биремнәрне аңлап, дөрес, үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга омтылып эшләү, | | |
| 3. | Сыйфатларны кабатлау. | Сыйфатны язма һәм телдән сөйләмдә куллана белү, аерым фикерләрне исбатлый һәм кире кага белү,<br>иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру,<br>әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү | | |
| 4. | Саннарны, алмашлыкларны кабатлау. | Саннарны язма һәм телдән сөйләмдә куллана белү, аерым фикерләрне исбатлый һәм кире кага белү. Җәйге каникулда кайда булуыңны, ничек ял итүеңне сөйли белү. Эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү, әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | | |
| 5 | Затланышлы фигыльләрне кабатлау | Фигыльләрне язма һәм телдән сөйләмдә куллана белү, аерым фикерләрне исбатлый һәм кире кага белү,<br>уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү, әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | | |
| 6. | Сүз төркемнәрен кабатлау буенча кереш контроль эш №1 | үзләштергән белемнәрне дөрес куллану, татар телендә язмача күнекмәләр булдыру. Белгәннәрне гомумиләштерә, мөһим мәгълүматларны аерып ала, мөстәкыйль эшли белү. Биремнәрне аңлап, дөрес, үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга омтылып эшләү | | |
| | **2. Белем һәм тормыш - 21 сәг.** | | | |
| 7 | Хаталар өстендә эш. Сыйфат. | Контроль эштә хата барлыгын, хата юклыгын әйтә белү. Сыйфатларның сүзтезмә төзүдәге роле һәм җөмләдәге урыны турында аңлату, сыйфатлы сүзтезмәләр төзү, бәйләнешле текстта аларны таба белү. | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү, әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү | | |
| 8 | Ясалма сыйфатлар. | -лы/-ле, -сыз/-сез кушымчалары ярдәмендә сыйфатлар ясый, аларны текстта таба белү, диалогик, монологик сөйләмдә куллану. Фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү, башкаларга карата түземлелек,игътибарлылык, кайгыртучанлык хисләре формалашу | | |
| 9 | Билгеле һәм билгесез үткән заман хикәя фигыль. | Фигыльләрне язма һәм телдән сөйләмдә куллана белү, аерым фикерләрне исбатлый һәм кире кага белү<br>эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү, әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү | | |
| 10 | Хикәя фигыльләрнең юклык формасы. **Каюм Насыйри белемле булуның кыйммәте турында.** | Билгеле үткән заман хикәя фигыльләрнең юклык формасын ясый белү, язма һәм телдән сөйләмдә дөрес куллана белү, төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлеген үз сүзләрең белән җиткерә белү. Үрнәк буенча парлап эшләү, сорауларга җавап бирү, парлап һәм төркемнәрдә эшләү күнекмәләре булдыру | | |
| 11 | Хәл фигыль | Хәл фигыльләр турында белешмә алу, мәгънәсен аңлау, аларны сөйләмдә дөрес итеп куллана белү, алар кергән җөмләләрне ишетеп аңлау, тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану, әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү, бер-береңә юл кую сыйфатын тәрбияләү | | |
| 12 | Хәл фигыльнең -ып/-еп/-п кушымчалы, кабатлаулы формасы | Хәл фигыльнең 1-, 2-төрләрен бәйләнешле сөйләмдә дөрес итеп куллану, аларны текстта аера белү,<br>фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү, әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү, бер-береңә юл кую сыйфатын тәрбияләү | | |
| 13 | Хәл фигыльнең -гач/-гәч, -кач/-кәч кушымчалы формасы. “Һәркем үзенчә хаклы” темасы буенча **аудирование** | Хәл фигыльнең икенче төрен аера белү, ишеткән текстның эчтәлеген аңлау<br>төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлеген үз сүзләрең белән җиткерә белү<br>Фикер туплау, биремне үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау, төгәл үтәргә омтылу | | |
| 14 | Хәл фигыльнең –ганчы/-гәнче кушымчалы формасы | Хәл фигыльнең 3-төрен бәйләнешле сөйләмдә дөрес итеп куллану, алар кергән җөмләләрне ишетеп аңлау,иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру<br>Үрнәк буенча парлап, төркемнәрдә эшләү, сорауларга җавап бирү, гомуми нәтиҗә чыгару. | | |
| 15 | Хәл фигыльләрне | сөйләмдә хәл фигыльнең төрле формаларын аера алу һәм дөрес куллану, алган белемнәрне | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кабатлау буенча **мөстәкыйль эш** | тикшерү максатыннан биремнәр эшләү, үзләштергән белемнәрне системага салырга өйрәтү, әхлак тәрбиясе бирү | | |
| 16. | Хаталарны төзәтү эше. **“Яхшы уку кагыйдәләре”** темасына **БСҮ** | “Яхшы уку кагыйдәләре” темасы буенча сөйләшүдә катнаша алу, сораулар бирү,фикер алышуда катнаша алу, укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү, әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү | | |
| 17 | Боерык фигыль | Киңәш һәм боеруны белдергән формаларны аңлау. Аларны сөйләмдә актив куллану. Үзлектән һәм парларда, төркемнәрдә эш, диктор артыннан кабатлау, тәрҗемә итү, әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | | |
| 18 | Боерык фигыльәрнең затта, санда төрләнеше | Боеруны һәм үтенечне, киңәш бирүне белдерүче җөмләләрне сөйләмдә куллану. Укучыларның сүзлек запасын баету. эш дәфтәрендә алган белемнәрне тикшерү максатыннан күнегүләр эшләү, әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү | | |
| 19 | Боерык фигыльләрнең юклык формсы | Фигыльләрне язма һәм телдән сөйләмдә куллана белү, аерым фикерләрне исбатлый һәм кире кага белү, төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү. Фикер туплау, биремне үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау, төгәл үтәргә омтылу | | |
| 20 | Боерык фигыльләрне кабатлау. **”Милли китапханә”** тмасына **Б.с.ү.** | Үзләштергән белемнәрне кулланып, текст өстендә эшләү, бәйләнешле сөйләм төзү, эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү. Фикер туплау, биремне үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау, аны нәтиҗәле үтәүгә омтылу | | |
| 21 | Рәвеш. | Рәвеш турында мәгълүмат алу, аларны сөйләмдә дөрес, урынлы куллану, төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү, башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык хисләре формалашу | | |
| 22 | Рәвеш төркемчәләре. | Рәвешләр турында белешмә алу, сөйләмдә дөрес, урынлы куллана алу, төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү, әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү | | |
| 23 | Саф рәвешләр | Саф рәвешләрне аерырга өйрәнү, аларны сөйләмдә актив куллану, төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү, әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү | | |
| 24 | Охшату-чагыштыру рәвешләре | Охшату-чагыштыру рәвешләрен аерырга өйрәнү, сөйләмдә дөрес куллану, эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү, Фикер туплау, биремне үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау, аны нәтиҗәле үтәүгә омтылу | | |
| 25 | “Сыйфат, рәвеш, исем” темалары буенча **контроль эш** №2 | Укчыларның фикерләү дәрәҗәсен үстерү, алган белемнәрне системалаштырырга өйрәтү.Уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү, алган белемнәрне тикшерү максатыннан контроль эш эшләү, игътибарлылык тәрбияләү | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 26 | Хаталарны төзәтү.Күләм-чама рәвешләре | Үзләштергән белемнәрне кулланып, күнегүләр эшләү, бәйләнешле сөйләм төзү, эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү. Төркемнәрдә сөйләшү, гомуми нәтиҗә чыгару, коллективта килешеп эшләргә омтылыш булдыру | | |
| 27 | Вакыт, урын рәвешләре | Вакыт, урын рәвешләрен аера белү һәм куллану күнекмәләре өстендә эш. “Көндәлек-документ, көндәлек –синең көзгең” темасына фикер алышуда катнашу, төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү, шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру | | |
| | | **2 нче чирек- 21сәг. 3. Без бергә ял итәбез - 38 сәг.** | | |
| 28 | Сәбәп һәм максат рәвешләре | Рәвеш төркемчәләрен сөйләмдә аера белү, сөйләм төзүдә активлаштыру, сүз байлыгын арттыру, төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү. Төркемнәрдә сөйләшү, гомуми нәтиҗә чыгару, коллективта килешеп эшләргә омтылыш булдыру | | |
| 29 | “күрә” бәйлеге. | Рәвешләрне сөйләм төзүдә активлаштыру, сүз байлыгын арттыру, “күрә” бәйлеген дөрес куллану.<br>Үзләштерелгән белемнәрне системалы куллана белү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү. Вакытны юкка сарыф итмәскә омтылыш тәрбияләү | | |
| 30 | Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе. | Татар телендә сүзләргә кушымчалар ялгау тәртибен аңлау, сөйләмдә үзләштергәннәрне актив куллану.<br>Үзләштерелгән белемнәрне системалы куллана белү, Уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү, әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү, игътибарлылык тәрбияләү | | |
| **31** | **Рәвешләрне кабатлау. “Казан парклары” темасына д.с.ү.** | Рәвеш төркемчәләрен сөйләмдә аера белү. Уку-язу әсбапларының кемнеке һәм нинди булуын әйтә белү,<br>төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү. Дөрес сөйләү, игътибарлы булу сыйфатларын формалаштыру | | |
| 32 | Сыйфат фигыль | Сыйфат фигыль турында төшенчә алу, аларны сөйләмдә дөрес итеп куллану, алар кергән җөмләләрне ишетеп аңлау, иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру, әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | | |
| 33 | Хәзерге заман сыйфат фигыль | Сыйфат фигыльнең хәзерге заманын бәйләнешле сөйләмдә куллану, тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану, әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү ,бер-береңне хөрмәт итү | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 34 | Үткән заман сыйфат фигыль | Сөйләмдә, текстларда сыйфат фигыльне таба алу, ишетеп аңлау, дөрес куллану. Уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү. Төркемнәрдә килешеп эшләү, башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык хисләре формалашу | | |
| 35 | “Минем ял көнем” темасына **хикәя төзү**. **Б.с.ү.** | Буш вакытны файдалы үткәрү турында сөйләшүдә катнаша, үз фикерләреңне әйтә алу, уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү, эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү. Буш вакытны дөрес файдаланырга омтылыш тәрбияләү | | |
| 36 | Киләчәк заман сыйфат фигыль | Сыйфат фигыльләрне аңлап куллану, тәрҗемә итә белү, сөйләмдә актив куллану. Уку эшчәнлеген оештыра белү, язма, телдән сөйләм төзүдә, тәрҗемә итүдә нәтиҗәле эшләү, шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру | | |
| 37 | Сыйфат фигыльләрнең юклык формасы**. Сүзлек диктанты** | сыйфат фигыльләрнең барлык һәм юклык формаларын ясый һәм сөйләмдә куллана белү, уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү. Фикер туплау, биремне үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау, җаваплылык тәрбияләү | | |
| 38 | Сыйфат фигыльнең сөйләмдә кулланылышы. | Сыйфат фигыльләрне дөрес кулланып, күнегүләр эшләү. Уку эшчәнлеген оештыра белү, язма, телдән сөйләм төзүдә, тәрҗемә итүдә нәтиҗәле эшләү, төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү | | |
| 39 | **“Без бергә ял итәбез” бүлеген кабатлау буенча административ контроль эш №3** | Үзләштерелгән белемнәрне системалы куллана белү. Укучыларның фикерләү дәрәҗәсен үстерү.<br>Төркемнәрдә сөйләшү, гомуми нәтиҗә чыгару, коллективта килешеп эшләргә омтылыш булдыру | | |
| 40 | Сыйфат фигыльләрне кабатлау. Тәрҗемә күнекмәләре | Алынган белемнәрне гамәли куллану, сыйфат фигыльләрне сөйләмдә актив куллану, эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү; әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү | | |
| 41 | “Көндәлек – документ, көндәлек - көзге” (әңгәмә-дәрес) **Б.с.ү.** | Уку эшчәнлеген оештыра белү, язма, телдән сөйләм төзүдә нәтиҗәле эшләү, төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү | | |
| 42 | “Сыйфат фигыльләр” темасы буенча **контроль эш №4** | Укучыларның фикерләү дәрәҗәсен үстерү, алган белемнәрне системалаштырырга өйрәтү.Уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү, алган белемнәрне тикшерү максатыннан контроль эш эшләү, игътибарлылык тәрбияләү | | |
| 43 | Хаталарны төзәтү эше. Җөмлә. Җөмләнең баш | Җибәргән хаталарны күрә, аңлап төзәтә белү, үзләштергән белемнәрне кулланып, сөйләм төзү. Җөмләнең баш кисәкләрен таба белү. Казан театрлары турында белешмә алу, сөйләм төзү, | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кисәкләре. | логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү, әңгәмәдәшенең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү, бер-береңә хөрмәт тәрбияләү | | |
| 44 | Ия һәм аның белдерелүе | Төрле сүз төркемнәренең ия була алуын белү, тулы җөмләләр кулланып, сөйләм төзи алу, фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү, әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | | |
| 45 | Хәбәр һәм аның белдерелүе | Төрле сүз төркемнәренең хәбәр була алуын белү, тулы җөмләләр кулланып, сөйләм төзи алу, укылган яки тыңланган тексттан ия, хәбәрне табу, әңгәмәдәш белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.<br>Татар сәнгатенә, мәдәниятына игътибар, кызыксыну формалаштыру | | |
| 46 | Ия һәм хәбәр арасында сызык куелу очраклары. | Ия һәм хәбәр арасында сызык куелу очракларын төшенү, ихтыяр көче,максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру, әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү | | |
| 47 | Җөмләнең баш кисәкләрен кабатлау. | Белемнәрне гомумиләштерү ,сөйләмдә актив куллануга ирешү, уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү, эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү; әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | | |
| 48 | Теркәгечләр.Теркәгечләрне төркемләү. | Теркәгечләр турында белгәннәрне искә төшерү, яңа белешмәләр алу, аларның җөмләдәге ролен аңлау,<br>укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү, әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү | | |
| | **3 нче чирек - 30 сәг.** | | | |
| 49 | **”Буш вакытым булса...”** темасы буенча **сочинение** | Буш вакытны файдалы,файдасыз үткәрү турында сөйләшүдә катнаша, үз фикерләреңне әйтә алу. Җөмләнең баш кисәкләрен дөрес кулланып, сочинение язу, уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү, эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү, Буш вакытны дөрес файдаланырга омтылыш тәрбияләү | | |
| 50 | Хаталарны төзәтү.Тезүче теркәгечләр.**“Казан театрлары”** темасы буенча **Б.с.ү.** | Тезүче теркәгечләрне җөмләдә аера һәм дөрес итеп куллана белү, театрлар турында белгәннәрне камилләштерү, иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру, җөмләләр төзү. Дөрес сөйләү, игътибарлы булу сыйфатларын формалаштыру | | |
